ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТАКТАЛАЧЫК АВЫЛ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423751, Такталачык авылы,
Г.Авзал ур., 48 нче йорт.
Тел.3-44-57

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АКТАНЫШСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ТАКТАЛАЧУКСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

423751, село Такталачук,
ул. Г.Авзал,дом 48,
Тел. 3-44-57

**КАРАР**

**06.04.2026ел.** **№8**

**Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге хезмәткәрләренең эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен раслау турында» 2023 елның 31 январендәге 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Актаныш районы прокурорының 27.03.2026 ел № 02-08-02-2026 номерлы протестын карап, Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл башкарма комитеты хезмәткәрләренең эчке хезмәт тәртибе Кагыйдәләрен раслау турында» 2023 елның 31 январендәге 5 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче кисәккә түбәндәге эчтәлекле 2.14_1 пунктчасы өстәргә:

«2.14_1. Һәлак булган (вафат булган) сугышчан хәрәкәтләр ветеранының кабат никахка кермәгән (өйләнмәгән) хатыны (ире) белән хезмәт шартнамәсен эш бирүче инициативасы белән өзү сугышчан хәрәкәтләр ветераны һәлак булган (үлгән) мизгелдән соң бер ел дәвамында рөхсәт ителми (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 81 статьясындагы беренче өлешенең 1, 5 - 8, 10 яисә 11 пунктларында яисә 336 статьясындагы 2 пунктында каралган нигезләр буенча эштән азат ителүдән тыш).»

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Т.Хузин